Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлегенең Пор-Кәтәш торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 24 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең Пор-Кәтәш торак пунктында халык җыены Карар кабул итте:

1. «95% күләмендә ташлама билгеләнгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы инвалидлар, ялгыз яшәүче пенсионерлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәкләрдән тыш, Урта Көшкәт авыл җирлегенең Пор-Кәтәш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 нче елда үзарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- янгынга каршы гидрант урнаштыру; балалар уен мәйданчыгын урнаштыру өчен җир участогын рәсмиләштерү, Үзәк урамында балалар уен мәйданчыгын урнаштыру, җиһазлау һәм төзеклəндерү, мәйдан периметры буенча коймалар урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю. М.